| МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

07.08.2023 Казан ш № 663

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы «Сиделка» хезмәте күрсәтүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә субсидия бирү турында килешүләр төзегән юридик затлар, шәхси эшкуарлар, шулай ук Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына караган өлкән яшьтәге гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү һәм кайгыртуга мохтаҗ инвалидларга социаль хезмәтләр күрсәтү учреждениеләре тарафыннан озак вакытлы социаль пакетка кертелгән карау буенча социаль хезмәтләр күрсәтү сыйфатына контрольлек башкару тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014-2025 елларга Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм күрсәтү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 елның 23 декабрендәге 1023 номерлы карары белән расланган 2014-2025 елларга «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм күрсәтү» дәүләт программасының 2014-2025 елларга «Татарстан Республикасы халкына социаль ярдәм күрсәтүне модернизацияләү һәм үстерү» ярдәмче программасына 5 нче кушымтада китерелгән 2023 елда Татарстан Республикасы территориясендә өлкән яшьтәге гражданнарны һәм карауга мохтаҗ инвалидларны озак вакытлы карау системасының бер төр моделендә каралган максатларга һәм бурычларга ярашлы рәвештә өлкән яшьтәге гражданнарны һәм карауга мохтаҗ инвалидларны озак вакытлы карау системасын булдыруның чаралар планы («юл картасы») нигезендә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы «Сиделка» хезмәте күрсәтүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә субсидия бирү турында килешүләр төзегән юридик затлар, шәхси эшкуарлар, шулай ук Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны

эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына караган өлкән яшьтәге гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү һәм кайгыртуга мохтаҗ инвалидларга социаль хезмәтләр күрсәтү учреждениеләре тарафыннан озак вакытлы социаль пакетка кертелгән карау буенча социаль хезмәтләр күрсәтү сыйфатына контрольлек башкару тәртибен (кушымтада бирелә) (алга таба – Тәртип) расларга.

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Татарстан Республикасы муниципаль районнарында (шәһәр округларында) социаль яклау идарәләре (бүлекләре), халыкка социаль хезмәт күрсәтүнең комплекслы үзәкләре, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының социаль хезмәт күрсәтү сыйфаты белән идарә итү бүлеге җитәкчеләренә Тәртип үтәлешен тәэмин итәргә.

3. Әлеге боерык үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры урынбасары Ю.И.Абдреевага йөкләргә.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2023 елның 7 августындагы 663 номерлы боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы «Сиделка» хезмәте күрсәтүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә субсидия бирү турында килешүләр төзегән юридик затлар, шәхси эшкуарлар, шулай ук Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына караган өлкән яшьтәге гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү һәм кайгыртуга мохтаҗ инвалидларга социаль хезмәтләр күрсәтү учреждениеләре тарафыннан озак вакытлы социаль пакетка кертелгән карау буенча социаль хезмәтләр күрсәтү сыйфатына контрольлек башкару тәртибе

1. Әлеге тәртип өлкән яшьтәге гражданнарга һәм карауга мохтаҗ инвалидларга озак вакытлы карауның социаль пакетына кертелгән карау буенча социаль хезмәтләр (алга таба – карау буенча социаль хезмәтләр) күрсәтүнең сыйфатын контрольдә тоту формаларын һәм ешлыгын билгели.

2. Озак вакытлы карауның социаль пакетына кертелгән өлкән яшьтәге гражданнарга һәм карауга мохтаҗ инвалидларга карау буенча социаль хезмәтләр күрсәтүнең сыйфатын контрольдә тотуны гамәлгә ашыру максаты (алга таба, тиешлечә, контроль, сыйфат контроле) булып түбәндәгеләр тора:

социаль хезмәтләр күрсәтү турында килешү шартлары үтәлешен тәэмин итү;

социаль хезмәтләр күрсәтүнең индивидуаль программаларын гамәлгә ашыруның (шул исәптән ярдәмченең үз вазыйфа бурычларын үтәвенең) нәтиҗәлелеген бәяләү.

3. Контрольлек Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы «Сиделка» хезмәте күрсәтүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә субсидия бирү турында килешүләр төзегән юридик затларга, шәхси эшкуарларга, шулай ук Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына караган өлкән яшьтәге гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү һәм кайгыртуга мохтаҗ инвалидларга социаль хезмәтләр күрсәтү учреждениеләренә (алга таба – социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүче) карата башкарыла.

4. Контрольдек предметы булып озак вакытлы карауның социаль пакетына кергән социаль хезмәтләр күрсәтүнең ешлыгы, күләме һәм сыйфаты тора.

5. Сыйфат контроле түбәндәгечә башкарыла:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының социаль яклау идарәләре (бүлекләре) (алга таба – социаль яклау территориаль органнары) тарафыннан Татарстан Республикасы муниципаль районнарында (шәһәр округларында) тиешле муниципаль район (шәһәр округы) чикләрендә;

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының социаль хезмәт күрсәтү сыйфаты белән идарә итү бүлеге (алга таба – Министрлыкның социаль хезмәт күрсәтү сыйфаты белән идарә итү бүлеге), шул исәптән Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) кысаларында да;

социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр, Россия Хезмәт министрлыгының «2023 елда Россия Федерациясенең аерым субъектларында өлкән яшьтәге гражданнарны һәм карауга мохтаҗ инвалидларны озак вакытлы карау системасының бер төр моделен гамәлгә ашыру турында» 2022 елның 15 декабрендәге 781 номерлы боерыгына ярашлы рәвештә төзелгән төбәк координация үзәге тарафыннан;

6. Сыйфат контроле документлар контролен, шул исәптән ведомство мәгълүмат системаларындагы мәгълүматларны, шулай ук социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүченең кайда булуы һәм гражданинга кайгырту буенча социаль хезмәтләр күрсәтү урыны буенча күчмә контрольне үз эченә ала.

7. Контроль чаралар кварталга 1 тапкыр (хисаптан соңгы айның 1-14 көне) һәм хезмәттән файдаланучыларның ким дигәндә 25 процентын колачлап башкарыла (ел йомгаклары буенча колач 100 процент тәшкил итәргә тиеш).

8. Гражданнарга социаль хезмәтләр күрсәтүнең сыйфатын контрольдә тотуны оештыру максатларында түбәндәгеләр гамәлгә ашырыла:

1) ведомство мәгълүмат системаларындагы мәгълүматлар нигезендә гражданинга социаль хезмәтләр күрсәтү турында мәгълүматны анализлау;

2) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2021-2024 елларда өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакытлы карау системасын гамәлгә ашыру чаралары турында» 2021 елның 13 февралендәге 77 номерлы карары, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибен раслау турында» 2014 елның 31 декабрендәге 1101 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибе, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында өйдә социаль хезмәт күрсәтү формасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибен раслау турында» 2014 елның 29 декабрендәге 1053 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында өйдә социаль хезмәт күрсәтү формасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибе нигезендә озак вакытлы карауның социаль пакетына кертелә торган карау буенча социаль хезмәтләрнең тәкъдим ителә торган

стандартлары буенча күрсәтелә торган социаль хезмәтләренең ярашлылыгын бәяләү;

3) карау буенча социаль хезмәтләр күрсәтүне раслаучы түбәндәге документларны анализлау:

социаль хезмәтләр күрсәтүнең индивидуаль программасы;

озак вакытлы карау буенча социаль пакетка кертелгән, бушлай бирелә торган социаль хезмәтләр күрсәтү турында хисаплар;

социаль хезмәтләр күрсәтү турында шартнамә;

социаль хезмәтләр күрсәтү турында актлар;

карау буенча ярдәмчеләрнең эш графигы;

индивидуаль карау планнары, карау көндәлекләре, шулай ук медицина патронажы;

социаль хезмәтләр күрсәтүдә формалаштырыла торган башка документлар.

9. Социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр, Россия Федерациясе Хезмәт министрлыгының «2023 елда Россия Федерациясенең аерым субъектларында өлкән яшьтәге гражданнарны һәм карауга мохтаҗ инвалидларны озак вакытлы карау системасының бер төр моделен гамәлгә ашыру турында» 2022 елның 15 декабрендәге 781 номерлы боерыгы нигезендә төзелгән төбәк координация үзәге тарафыннан социаль хезмәтләр күрсәтүнең сыйфатын агымдагы контрольдә тоту даими нигездә гамәлгә ашырыла.

10. Агымдагы контроль түбәндәгеләрне үз эченә ала:

1) гражданинга социаль хезмәтләр күрсәтү кысаларында карау буенча ярдәмче тарафыннан рәсмиләштерелә торган документларны анализлау (социаль хезмәтләр күрсәтү турында актлар, озак вакытлы карауның социаль пакетына кертелгән, гражданинга өйдә социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә бушлай бирелә торган социаль хезмәтләр күрсәтү буенча хисаплар);

2) ярдәмченең үз вазыйфаларын башкаруын бәяләү.

11. Агымдагы контроль барышында ачыкланган бозулар кичекмәстән бетерелергә тиеш.

12. Министрлыкның социаль яклау буенча территориаль органы, социаль хезмәт күрсәтү сыйфаты белән идарә итү бүлеге тарафыннан үткәрелгән контроль нәтиҗәләре әлеге Тәртипкә кушымтада китерелгән форма буенча өч нөсхәдәге акт белән рәсмиләштерелә. Актның бер нөсхәсе хисап чорыннан соңгы айның 15 нче көненә кадәр социаль хезмәт күрсәтү мәсьәләләрен алып баручы министр урынбасары адресына бирелә, актның икенче нөсхәсе социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчедә кала, өченче нөсхә – сыйфат контролен гамәлгә ашыручы затта.

13. Актларны саклау вакыты 5 ел тәшкил итә.

14. Социаль хезмәтләрдән файдаланучы затка барганда, контрольлек чарасын үткәрүче зат түбәндәге гамәлләрне башкара:

гражданин, аның законлы вәкиле, шулай ук карауны гамәлгә ашыручы зат (катнашучылар арасыннан) белән әдәпле таныша, визитның максатларын аңлата (визитның дәвамлылыгы 60 минуттан артмаска тиеш);

гражданин, аның законлы вәкиле, карауны гамәлгә ашыручы зат (катнашучылар арасыннан) белән әңгәмә кора, социаль хезмәтләр күрсәтү

буенча искәрмәләр булу-булмавын, аларны күрсәтүнең тулылыгын, вакытында күрсәтелүен ачыклау максатыннан сораулар бирә;

социаль хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләренең һәм аларның сыйфатының тәртипләргә туры килүен, яңа хезмәтләр күрсәтүгә ихтыяҗ булу-булмавын ачыклый;

нигезләр булганда, аерым социаль хезмәтләрнең өлешчә күрсәтелү яки күрсәтелмәү сәбәпләрен ачыклый.

15. Әгәр сөйләшү мөмкинлеге булмаса яки хезмәттән файдаланучы затка бару мөмкинлеге булмаса, сәбәпләрен күрсәтеп, актта язу теркәлә.

16. Сыйфат контроле кысаларында тикшерү үткәрү турында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчегә контрольлек чарасын үткәрүче зат тарафыннан чара башланганчы 2 эш көненнән дә соңга калмыйча хәбәр ителергә тиеш.

17. Акт нигезендә социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчегә ачыкланган хокук бозуларны бетерү буенча чаралар күрү өчен тәкъдимнәр җибәрелә.

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы «Сиделка» хезмәте күрсәтүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә субсидия бирү турында килешүләр төзегән юридик затлар, шәхси эшкуарлар, шулай ук Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына караган өлкән яшьтәге гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү һәм кайгыртуга мохтаҗ инвалидларга социаль хезмәтләр күрсәтү учреждениеләре тарафыннан озак вакытлы социаль пакетка кертелгән карау буенча социаль хезмәтләр күрсәтү сыйфатына контрольлек башкару тәртибенә кушымта

*(формасы)*

АКТ № __________ _______________

озак вакытлы карау буенча социаль пакетка кертелгән өлкән яшьтәге гражданнарга һәм карауга мохтаҗ инвалидларга социаль хезмәтләр күрсәтү сыйфатын контрольдә тоту нәтиҗәләре турында

_______________________________________________________________________

_______________________________________________________________________

(муниципаль район (шәһәр округы), сыйфат контролен гамәлгә ашыручы затның вазыйфасы, фамилиясе, исеме, атасының исеме)

социаль хезмәтләр күрсәтүнең сыйфатын контрольдә тоту максатыннан

_______________________________________________________________________

_______________________________________________________________________

(социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүченең атамасы, социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүче затның вазыйфаи заты)

урынга чыгылды:__________________________________________________

_______________________________________________________________________

(яннарына бару гамәлгә ашырылган хезмәт алучыларның адреслары санын күрсәтергә)

телефон аша сөйләшү булды:_______________________________________

_______________________________________________________________________

(телефоннан сөйләшкән гражданнарның санын күрсәтергә)

1. Контрольлек чарасы нәтиҗәләре:

1.1 Килү нәтиҗәләре буенча:

| Т/с | Гражданинның фамилиясе, исеме, ата исеме (булган очракта) | Озак вакытлы карау буенча социаль пакетка керүче | Озак вакытлы карау буенча социаль пакетка кертелгән, тәкъдим ителгән социаль хезмәтләр | Социаль хезмәтләр күрсәтүнең ешлыгын үтәү (әйе/юк) | Социаль хезмәтләр күрсәтүнең озак вакытлы социаль пакетына кертелгән | Социаль хезмәтләр күрсәтүне раслаучы документлар булуы |
|---|---|---|---|---|---|---|

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | тәкъдим ителгән социаль хезмәтләр исемлеге (саны) | исемлеге һәм өлкән яшьтәге гражданнарга һәм карауга мохтаҗ инвалидларга бирелә торган социаль хезмәтләр исемлеге арасындагы аерманың сәбәбе | | социаль хезмәтләрнең киңәш ителгән стандартлары на туры килүе | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |

1.2 Гражданин белән әңгәмә нәтиҗәсе

| т/с | Гражданинның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта) | Искәрмәләр булуы (бар икән – күрсәтергә) | Карау хезмәтләренә ихтыяҗ (бар икән – күрсәтергә) | Искәрмәләр |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |
| | | | | |

Искәрмәләр һәм тәкъдимнәрсез җаваплар ________________________________________

(исәбен күрсәтергә)

1.3 Түбәндәге шартлар буенча тикшерүне үткәрүе мөмкин түгел:

____________________________________________________________________________

(тикшерү үткәрү мөмкин булмаган шартлар күрсәтелә)

2. Нәтиҗәләр.

2.1 Бәяләмә

____________________________________________________________________________

2.2 Кимчелекләрне бетерү буенча тәкъдимнәр һәм киңәшләр

____________________________________________________________________________

Акт төзелде____________________________________________________________

____________________________________________________________________________

(контроль уздырган затның вазыйфасы, фамилиясе, исеме, атасының исеме, имзасы)

Акт белән таныштым ____________________________________________________
_____________________________________________________________________________

(социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүче вәкиленең вазыйфасы, фамилиясе, исеме, атасының исеме, имзасы)